ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.02.2019 Алексеевск ш.т.б. № 69

**“Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты турында” Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты Карарынаүзгәрешләр кертү турында**

Федераль законнар таләпләренә туры китерү, “Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты үрнәк формасына үзгәрешләр кертү турында”гы ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 26 декабрь 2018 ел, 1975/18 нче санлы боерыгы (ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 10 март, 2015 ел, 1389/15нче санлы боерыгы белән расланган) нигезендә “Мәктәпкәчә белем бирү (балалар бакчалары) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм кабул итү” муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында”гыАлексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 3 август, 2018 ел, 229 нчы карарына (26 ноябрь, 2018 ел үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

**карар бирәм:**

3 нче пункта:

3.4.4 пунктчага түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

“Ташламаның билгеләнгән гамәлдәге срогы чыккач, оешмага гариза бирүченең чираттан тыш яки беренче чиратта кабул итү хокукын расларга кирәк”;

3.4.6 пунктчаның 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Уку елы дәвамында буш урыннар булганда Административ регламентның 3 нче пунктында каралган тәртип нигезендә оешма комплектлап бетерелә”;

3.4.6 пунктчаның 4 нче абзацын бетерергә;

3.4.6 пунктчаның 6 нчы абзацында “кимендә 5 эш көне дәвамында” сүзләрен “Бер ай дәвамында” дигән сүзләргә алмаштырырга;

3.5.2 пунктчаның 3 нче абзацында “ Өч ай дәвамында” дигән сүзләрне “Бер ай дәвамында” дигән сүзләргә алмаштырырга;

3.5.4 пунктчаның 1 нче абзацын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Теләгән кабул итү көне гариза бирүче юлламадан баш тартуы турында мөрәҗәгать иткән көннән иртәрәк булмаган көнгә алмаштырыла”.

3.5.5 пунктчаның 1 нче абзацында “Оешма җитәкчесе гаризага Системада “Килмәде” статусыбирә дигән сүзләрне “Системада гаризага “Килмәде” статусы бирелә” дигән сүзләргә алмаштырырга;

3.5.6 пунктның 1 нче абзацын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Раслаганда теләгән кабул итү көне муниципаль хезмәткә ихтыяҗны раслап, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көннән иртәрәк булмаган көнгә алмаштырыла”;

3.6.2. пунктның 2 нче абзацында “Өч айлык срок” сүзләрен “Айлык срок” дигән сүзләргә алмаштырырга;

3.6.3 пунктның 1 нче абзацын түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга:

“Раслаганда теләгән кабул итү көне муниципаль хезмәт алуга ихтыяҗны раслап, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көннән иртәрәк булмаган көнгә алмаштырыла”;

2. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне “Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе начальнигы Д.Ә. Гыйләҗевка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**